**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"19" ноябрь 2023 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә торак пунктында халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларнын гаилә әгъзаларын, РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш, хәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Яңа Әтнә авылы урамнары юлларын төзекләндерү (таш белән каплау эшләре буенча хезмәтләр өчен түләү);

2) Урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру һәм ремонт өчен материаллар сатып алу);

3. 2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән Яңа Әтнә авылы Яшьләр урамы юлына асфальт җәю чен 50000 сум күләмендә гражданнарның кулланылмаган үзара салымы акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Яңа Әтнә авылы Совет, Яшьләр, Садовая,Новая һәм Дуслык урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү һәм каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чүп-чарны чистарту);

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Әтнә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Әтнә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: Порфирьев С.Н.